СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРЖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.06.2021 Әгерже шәһәре № 10-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының административ комиссиясен төзүгә җирле үзидарәнең вәкаләтле органын билгеләү турында

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясындагы 2 өлешенең 24.1 пункты, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы 1 өлешендә, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану турында» 2020 елның 19 ноябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Административ комиссияләр турында» 2020 елның 10 декабрендәге 11/13-09/6231 номерлы, «Административ комиссияләр турында» 2020 елның 30 декабрендәге 11/13-09/6750 номерлы хезмәт хатларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетын административ комиссия төзүгә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының административ комиссиясен төзергә;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының административ комиссиясе составын расларга;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының административ комиссиясе эше регламентын расларга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru)

урнаштырырга, «Татмедиа» АҖ филиалы филиалының вакытлы матбугат басмасында - «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») Әгерҗе районы газетасында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җирле үзидарә буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев